# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

## Энергияне сак тоту турында

Әлеге Закон, энергия ресурсларыннан файдалану нәтиҗәлелеген арттыруның икътисадый һәм оештыру шартларын булдыру өчен, энергияне сак тоту өлкәсендәге эшчәнлек процессында барлыкка килүче мөнәсәбәтләрне җайга сала.

### I бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1 статья. Төп төшенчәләр

Әлеге Законда түбәндәге төшенчәләр кулланыла:

энергияне сак тоту - энергия ресурсларыннан нәтиҗәле файдалануга һәм энергиянең яңадан торгызыла торган чыганакларын хуҗалык әйләнешенә кертүгә юнәлдерелгән хокукый, оештыру, фәнни, җитештерү, техник һәм икътисадый чараларны гамәлгә ашыру;

дәүләтнең энергияне сак тоту сәясәте - энергияне сак тоту өлкәсендәге эшчәнлекне хокукый, финанс-икътисадый яктан һәм оештыру ягыннан җайга салу;

энергия ресурслары - хәзерге вакытта файдаланыла торган яисә киләчәктә файдаланырга мөмкин булган энергия чыганаклары;

энергия ресурсларыннан нәтиҗәле файдалану - техника һәм технологияләрнең үсеше хәзерге дәрәҗәдә булганда һәм әйләнә-тирә табигать мохитен саклау таләпләрен үтәгәндә энергия ресурсларыннан файдалануның икътисадый нәтиҗәлелегенә ирешү;

энергия нәтиҗәлелеге күрсәткече - теләсә нинди максатлардагы продукция өчен сарыф ителә яисә югалтыла торган энергия ресурсларының дәүләт стандартлары белән билгеләнгән абсолют яисә чагыштырма күләме;

энергия ресурсларының җитештерүчән булмаган чыгымы - дәүләт стандартлары белән билгеләнгән таләпләрнең үтәлмәве аркасында, шулай ук башка норматив актлар белән, технологик регламентлар һәм гамәлдәге җиһазлар өчен паспорт мәгълүматлары белән билгеләнгән таләпләрне бозу аркасында энергия ресурсларының чыгымы;

энергиянең яңадан торгызыла торган чыганаклары - кояш, җил, җир җылысы, су агымнарының табигый хәрәкәте энергиясе, шулай ук табигатьтәге температура градиентларының энергиясе;

ягулыкның альтернатив төрләре - файдалану нәтиҗәсендә энергия ресурсларының электән килгән ягулыкны тотуны кыскарта яисә аларны алмаштыра торган ягулык төрләре (кысылган һәм сыеккландырылган газ, биогаз, генератор газы, биомассаны эшкәртү продуктлары, су-күмер ягулыгы һәм башкалар).

2 статья. Энергияне сак тоту өлкәсендә хокукый җайга салу

Энергияне сак тоту өлкәсендә хокукый җайга салу әлеге Закон һәм башка закон актлары белән гамәлгә ашырыла.

3 статья. Бу Законны куллану өлкәсе

Әлеге Закон Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә була һәм түбәндәгеләргә юнәлтелә:

энергия ресурсларын чыгарганда, җитештергәндә, эшкәрткәндә, транспортлаганда, саклаганда һәм кулланганда алардан нәтиҗәле файдалану;

энергия ресурсларыннан нәтиҗәле файдалануга дәүләт күзәтүен гамәлгә ашыру;

ягулыкның кыйммәтрәк һәм дефицитрак төрләрен алмаштырырга сәләтле булган энергетик ресурсларны чыгаруны, җитештерүне һәм алардан файлалануны үстерү;

энергиянең нәтиҗәле технологияләрен, ягулык, энергия кулланучы һәм диагностика җиһазларын, конструкция һәм изоляция

материалларын, энергия ресурслары чыгымын исәпкә алу приборларын, энергия куллануны автомат рәвештә идарә итү системаларын булдыру һәм алардан файдалану;

җибәрелә торган һәм кулланыла торган энергия ресурсларын исәпкә алуда төгәллекне, дөреслекне һәм бердәйлекне тәэмин итү.

4 статья. Татарстан Республикасында энергияне сак тоту сәясәтенең төп принциплары

Татарстан Республикасының энергияне сак тоту сәясәте түбәндәге принципларга нигезләнә:

ягулыктан һәм энергиядән файдалануның нәтиҗәлелеген күтәрүнең аларны табу, җитештерү һәм эшкәртү күләмен арттыру белән чагыштырганда өстенлекле булуы;

җитештерүнең нәтиҗәлелеген арттыру һәм энергия ресурсларыннан файдалану программаларын һәм проектларын дәүләт тарафыннан кызыксындыруны һәм аларга финанс ярдәме күрсәтүне тәэмин итү;

энергия ресурсларыннан нәтиҗәле файдалануга дәүләт күзәтүен гамәлгә ашыру;

юридик затларның үзләре җитештерә яки сарыф итә торган энергия ресурсларын исәпкә алуының, шулай ук физик затларның үзләре куллана торган энергия ресурсларын исәпкә алуының мәҗбүрилеге;

технологияләрнең, җиһазларның, материалларның һәм конструкцияләрнең, транспорт чараларының дәүләт стандартларына аларның энергия нәтиҗәлелеге күрсәткечләрен кертү;

аз экономияле энергетика җиһазларын һәм энергия нәтиҗәлелеге күрсәткечләре энергия куллануның норматив таләпләреннән кимрәк булган җиһазларны файдаланудан этаплап төшереп калдыру;

энергия ресурсларын кулланучыларның, аларны бирүчеләрнең һәм җитештерүчеләрнең мәнфәгатьләрен яраштыру.

## II бүлек. Энергияне сак тоту өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнарының компетенциясе

<u>5 статья.</u> Энергияне сак тоту өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнарының компетенциясе

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы үз компетенциясе чикләрендә:

энергияне сак тоту өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне законнар белән җайга салуны гамәлгә ашыра;

энергияне сак тоту өлкәсендә Татарстан Республикасы сәясәтенең төп юнәлешләрен билгели;

энергияне сак тотуның мөһим республика программаларын һәм аларны бюджеттан финанслауның күләмнәрен раслый.

2. Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты:

әлеге Закон нигезендә энергияне сак тотуның дәүләт программаларын эшли, норматив-хокукый актлар кабул итә;

Татарстан Республикасында энергияне сак тоту сәясәтен гамәлгә ашыру буенча үзләре төзегән бюджеттан тыш дәүләт учреждениеләре эшен җайга сала (Татарстан Республикасы буенча Энергия күзәтчелеге дәүләт инспекциясе, Энергияне сак тоту технологияләренең республика үзәге);

энергияне сак тотуның республика программаларын гамәлгә ашыручы оешмаларга дәүләт ярдәме күрсәтү мәсьәләләрен хәл итә;

Татарстан Республикасы Дәүләт Советына ел саен ягулык һәм энергиядән нәтиҗәле файдалану турында хисап бирә.

3. Дәүләт хакимияте һәм идарәсенең җирле органнары үз компетенциясе чикләрендә:

энергияне сак тотуның республика программаларын эшләүдә һәм гамәлгә ашыруда катнаша;

энергияне сак тотуның республика программаларына һәм җирле программаларга керүче гамәлләрнең үтәлүен тикшереп тора;

энергияне сак тоту гамәлләрен үтәү барышында дәүләт финанс чараларын куллануны тикшереп тора.

## Ш бүлек. Энергияне сак тотуның дәүләт идарәсе нигезләре

6 статья. Энергияне сак тоту өлкәсендә идарә итүнең төп принциплары

Энергияне сак тоту өлкәсендә идарә итүнең төп принциплары энергияне сак тоту өлкәсендә федераль, төбәкара һәм республика программаларын гамәлгә ашыру процессында түбәндәге юллар белән тормышка ашырыла:

ягулыкны һәм энергияне сак тота торган җиһазлар җитештерүне һәм алардан файдалануны кызыксындыру;

энергия ресурсларын тотуны исәпкә алуны, шулай ук аларны сарыф итүне тикшереп торуны оештыру;

энергия ресурсларыннан нәтиҗәле файдалануга дәүләт күзәтүен гамәлгә ашыру;

оешмаларда энергия тикшеренүләре үткәрү;

проект документларына энергия экспертизасы үткәрү;

энергиянең югары нәтиҗәлелегенең күрсәтмә проектларын гамәлгә ашыру;

энергияне сак тоту өлкәсендә икътисадый, мәгълүмати уку-укыту һәм башка юнәлешләрне гамәлгә ашыру.

7 статья. Энергия ресурсларыннан нәтиҗәле файдалануга дәүләт күзәтүен гамәлгә ашыру һәм энергияне сак тоту өлкәсендәге эшчәнлекне координацияләү

Энергия ресурсларыннан нәтиҗәле файдалануга һәм түбәндәгеләрне тикшереп торучы Татарстан Республикасы буенча Энергия күзәтчелеге дәүләт инспекциясенә йөкләнә.

Энергияне сак тоту өлкәсендәге эшчәнлекне координацияләүне, бәяләр билгеләүне, оештыруны һәм финанс-икътисадый җайга салуны да кертеп, Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты башкара.

8 статья. Оешмаларда энергия тикшеренүләре үткәрү

Оешмаларда энергия тикшеренүләре энергия ресурсларыннан

нәтиҗәле файдалануга бәя бирү, ягулык һәм энергия белән тәэмин ителүгә кулланучыларның чыгымнарын киметү максатларында үткәрелә.

Оештыру-хокукый һәм милек рәвешләренә карамастан, оешмаларның энергия ресурсларын еллык кулланулары алты тоннадан артык шартлы ягулык яисә бер тоннадан артык мотор ягулыгы тәшкил итсә, аларда энергия тикшеренүләре мәҗбүри рәвештә үткәрелә.

Энергия ресурсларын әлеге статьяның икенче өлешендә күрсәтелгәннән кимрәк кулланган объектларда энергия тикшеренүләре Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты яисә ул вәкаләт биргән дәүләт идарәсе органы карары белән үткәрелә.

9 статья. Энергия ресурсларын исәпкә алу

Табыла, җитештерелә, эшкәртелә, транспортлана, саклана һәм кулланыла торган энергия ресурсларының бөтен күләме мәҗбүри рәвештә исәпкә алынырга тиеш. Бюджет оешмаларын энергия ресурсларын исәпкә алу приборлары белән тәэмин итү тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан билгеләнә.

Кулланыла торган энергия ресурсларын исәпкә алу билгеләнгән дәүләт стандартлары һәм үлчәү төгәллеге нормалары нигезендә гамәлгә ашырыла.

10 статья. Энергия ресурсларын куллануга һәм алардан нәтиҗәле файдалануга дәүләт статистика күзәтүе

Энергия ресурсларын куллануның күләме һәм структурасы, алардан нәтиҗәле файдалану буенча дәүләт статистика күзәтүен Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан билгеләнә торган тәртиптә Татарстан Республикасының Статистика буенча дәүләт комитеты оештыра һәм уздыра.

IV бүлек. Энергияне сак тоту өлкәсендә стандартлаштыру һәм сертификацияләү

11 статья. Стандартлаштыру

Энергия нәтиҗәлелеге күрсәткечләрен эченә алган стандарт-

лар законнарда каралган тәртиптә билгеләнә.

Энергия ресурсларын тапканда, җитештергәндә, эшкәрткәндә, транспорт белән ташыганда, саклаганда һәм кулланганда алардан нәтиҗәле файдалануның күрсәткечләре, шулай ук биналарны җылытуга, җилләндерүгә, кайнар су белән тәэмин итүгә һәм яктыртуга энергия сарыф итүнең күрсәткечләре, җитештерү процессларының энергия куллану буенча башка күрсәткечләре билгеләнгән тәртиптә тиешле норматив-техник документларга кертеләләр.

Энергияне куллану өлкәсендә Россия Федерациясенең дәүләт стандартлары тарафыннан куела торган таләпләрне Татарстан Республикасы территориясендә үтәү мәҗбүри.

Яңадан торгызыла торган энергия чыганакларыннан һәм энергияне сак тотуның республика программалары нигезендә корыла торган энергия җайланмаларыннан файдаланучы энергия корылмалары төзелешкә киткән капиталь салуларны сигез елдан да соңламыйча каплауны тәэмин итәргә тиеш.

<u>12 статья.</u> Сертификацияләү

Энергия куллану продукциясе, энергия нәтиҗәлелегенең тиешле күрсәткечләренә мәҗбүри сертификацияләү узарга тиеш. Мәҗбүри сертификацияләү законнарда билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасында стандартлаштыру, метрология һәм сертификацияләүне башкаручы орган тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Энергия ресурсларын тапканда, җитештергәндә, эшкәрткәндә, транспортлаганда, саклаганда һәм кулланганда, шулай ук аларны сертификацияләгәндә энергияне сак тоту өлкәсендә мәҗбүри дәүләт метрология тикшереп торуы һәм күзәтүе гамәлгә ашырыла.

Җитештерелә торган көнкүреш җиһазларының энергия куллану күрсәткечләре буенча билгеләнгән дәүләт стандартларына туры килүе әлеге җиһазларны мәҗбүри тамгалау юлы белән раслана.

## V бүлек. Энергияне сак тоту икътисадый һәм финанс ягыннан тәэмин итү

### 13 статья. Энергияне сак тоту өлкәсендәге программаларны финанслау

Энергияне сак тотуның республика һәм җирле программаларын гамәлгә ашыру өчен финанс чаралары түбәндәгеләр хисабына оеша:

Татарстан Республикасының Республика бюджеты, җирле бюджетлар акчалары;

дәүләт акчалары исәбеннән финанслана торган энергияне сак тоту программаларын, проектларын, гамәлләрен тормышка ашыру нәтиҗәсендә экономияләнгән энергия ресурсларыннан килә торган акчалар;

инвесторлар акчалары, шулай ук, предприятиеләрнең үз акчаларын да кертеп, законнарда билгеләнгән тәртиптә башка чыганаклар.

Энергияне сак тоту өлкәсендә акчаларны оештыру һәм тоту тәртибе Министрлар кабинеты тарафыннан билгеләнә.

### 14 статья. Энергия ресурсларын кулланучыларга һәм аларны җитештерүчеләргә өстенлекле ташламалар

Энергия ресурсларын кулланучыларга һәм аларны җитештерүчеләргә энергияне сак тоту хисабына куллануны һәм җитештерүне дәүләт стандартларында билгеләнгәнгә караганда яхшырак күрсәткечләр белән башкарганнары өчен законнарда каралган өстенлекле ташламалар бирелергә мөмкин.

Энергия ресурсларыннан нәтиҗәле файдалануны кызыксындыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты энергия ресурсларына сезонлы бәяләр һәм дифференциацияләнгән тарифлар билгели.

## VI бүлек. Энергияне сак тоту өлкәсендә халыкара хезмәттәшлек

15 статья. Энергияне сак тоту өлкәсендә халыкара хезмәттәшлек

Татарстан Республикасында энергияне сак тоту өлкәсендә халыкара хезмәттәшлек законнар нигезендә гамәлгә ашырыла.

Әгәр Татарстан Республикасының һәм Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә әлеге Законда каралгандагыдан үзгә кагыйдәләр билгеләнгән булса, халыкара шартнамә кагыйдәләре кулланыла.

## VII бүлек. Энергияне сак тотуның мәгълүмати тәэмин ителеше

16 статья. Энергияне сак тотуның мәгълүмати тәэмин ителеше

Энергияне сак тотуның мәгълүмати тәэмин ителеше түбәндәге юллар белән гамәлгә ашырыла:

энергияне сак тотуның республика һәм җирле программаларын тикшерү;

югары нәтиҗәле энергиянең күрсәтмә проектларын һәм энергияне сак тотуның технология проектларын әзерләү буенча эшләрне координацияләү;

энергия ресурсларын кулланучыларга энергияне сак тоту мәсьәләләре буенча мәгълүмат бирү;

энергия ресурсларыннан нәтиҗәле файдалануны пропагандалау.

## VIII бүлек. Энергияне сак тоту турындагы законнарны бозган өчен җаваплылык

17 статья. Энергияне сак тоту турындагы законнарны бозган өчен җаваплылык

Әлеге Закон нигезләмәләрен бозуда гаепле затлар гамәлдәге законнар нигезендә җаваплы булалар.

Җирле администрацияләр каршындагы административ комиссияләр тарафыннан салынган штрафлардан кергән акча квартал саен түбәндәге тәртиптә бүленә: 60 проценты - Татарстан Республикасының республика бюджетына, 40 проценты - җирле бюджетларга.

IX бүлек. Йомгаклау нигезләмәләре

18 статья. Әлеге Законны гамәлгә кертү турында

Әлеге Законны матбугатта басылып чыккан көненнән гамәлгә кертергә.

Татарстан Республикасы
Президенты М.Шәймиев

Казан шәһәре,
1998 елның 21 октябре
N 1816